# КАРАР

27 ноябрь, 2024 ел №1

**Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Пчеловод авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 27 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Пчеловод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

*тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау* (Пчеловод авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, карап тоту, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- *торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту* (Пчеловод авылы юлларына вак таш салу һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(Пчеловод авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машинист-тракторчы хезмәтләре)

- *су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары проектлау, төзү һәм ремонтлау* (насослар сатып алу, урнаштыру һәм артезиан скважиналарын, су суырту манараларын, су саклау зоналарын карап тоту)

(Пчеловод авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм йорт хуҗалыкларын гамәлдәге линиягә тоташтыру; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Пчеловод авылының чишмә янында ял итү зоналары территорияләрен, балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 197 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 112 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 112 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пчеловод авыл җирлегенең Поршур авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга.

2. 2025 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Пчеловод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне расларга карар кылдык:

*тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау* (Пчеловод авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, карап тоту, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

- *торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту* (Пчеловод авылы юлларына вак таш салу һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(Пчеловод авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, чапкыч, запас частьләр сатып алу, машинист-тракторчы хезмәтләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(Пчеловод авылында кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территориянең печәнен чабу, төзекләндерү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен

түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре) проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(тукталыш павильоннары сатып алу, ясау һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(юл билгеләрен һәм тамгаларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

- *су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары проектлау, төзү һәм ремонтлау* (насослар сатып алу, урнаштыру һәм артезиан скважиналарын, су суырту манараларын, су саклау зоналарын карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(Пчеловод авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм йорт хуҗалыкларын гамәлдәге линиягә тоташтыру; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- *янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү* (янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне, колонкаларны, мотопомпаны карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Пчеловод авылының чишмә янында ял итү зоналары территорияләрен, балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары-Чура авыл җирлеге башлыгы: Р.Т. Мифтахов